**Кодалар –кодачалар** (Сөләйман Латыпов)

Бәзәкә авылы мәдәният йортында 7 февраль көнне БУА ДӘҮЛӘТ САТИРА ТЕАТРЫ чыгыш ясады. Тамашачы хозурына алар Сөләйман Латыповнын “Кодалар - кодачалар” комедиясен тәкъдим иттеләр. Артистларның осталыкларына исең китәрлек. Алар һәрберсе үз рольләрен яратып, җиренә җиткереп башкарды. Ул көнне буран булу сәбәпле халык саны артык күп булмаса да, көчле алкышлар бер минутка да тынып тормады, тамашачы рәхәтләнеп сәһнәдә барган туй мәҗлесендә күңел ачты, ял итте.

Театрның җитәкчесе Татарстанның Халык артисты Раил Илдар улы Садриевка, спектакльдә катнашкан артистларыбызга зур рәхмәт сузләрен җиткерәсебез килә. Ерак араларны якын итеп, ел саен безнең авылыбызга килеп чыгыш ясауларына без чиксез шатбыз!  Ике арадагы дуслык җепләре нык булсын, киләсе елларда да яңа программаларыгызны, матур чыгышларыгызны Бәзәкә авылында күрергә язсын-дигән теләктә калабыз!  (февраль 2019 ел)




07-02-19 21:26


"....Туган җирнең яме -
яшэешнең тәме,
Тамыр җәйгән безнең йөрэктэ"
М. Гимазетдинов


07-02-19 18:13




DOUBLE
FITNESS
MAFIA